**СОВЕТ ГОРОДА МАМАДЫШ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**ул. М. Джалиля, 23/33, г. Мамадыш, 422190**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**
**М.Җәлил ур., 23/33, Мамадыш ш., 422190**

тел.:(85563) 3-15-90, факс 3-24-00 ; e-mail:gorsovet.mamadysh@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 3-15** **«21» август 2023 ел**

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки гражданлык процессуаль законнары белән билгеләнгән тәртиптә аны үлгән дип игълан итү, әгәр закон буенча да һәм васыять буенча да варислар булмаса яисә варисларның берсе дә мирас алырга хокуклы түгел яки барлык варислар да мирас алудан читләштерелгән, яисә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, яисә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән;

2) салым түләүченең гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срокның тәмамлануы;

4) гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән өч еллык срокның тәмамлануы.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Советының «Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм

бу салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2016 елның 3 октябрендәге 3-11 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәренең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге каранын үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре башлыгы,
шәһәр Советы рәисе А.П. Иванов